КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1117

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 644 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче; 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче; 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы; 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 13 май, 281 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының

дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең 1 бүлегендә:

1.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Бу Тәртип максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

Татарстан Республикасының дәүләт программасы (алга таба – дәүләт программасы) – Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү максатларына һәм аның бурычларын хәл итүгә нәтиҗәлерәк ирешүне тәэмин итә торган һәм бурычлар, гамәлгә ашыру вакытлары, үтәүчеләр һәм ресурслар буенча үзара яраштырылган планлаштырыла торган чаралар комплексыннан гыйбарәт стратегик планлаштыру документы;

дәүләт программасының ярдәмче программасы – дәүләт программасының дәүләт заказчысы-яраштыручысы тарафыннан билгеләнә торган, аның максатларына ирешүгә һәм аерым бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы;

ведомство максатчан программасы – дәүләт программасының ярдәмче программасындагы билгеле бер бурычны хәл итүгә юнәлдерелгән, яраштырылган чаралар комплексыннан, шулай ук үлчәнә торган максатчан индикаторлардан гыйбарәт документ. Ведомство максатчан программасы мөстәкыйль документ булып тора;

чаралар планы – программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруны күздә тота торган һәм үтәүчеләре, вакытлары, ресурслары һәм соңгы нәтиҗәләре күрсәтелгән чаралар җыелмасы;

проект – вакыт һәм ресурс белән чикләнгән шартларда төгәл куелган максатларга ирешүгә юнәлдерелгән һәм үзара бәйләнгән, бер тапкыр башкарыла торган чаралар комплексы;

проектлар портфеле – бердәм максатка ирешү өчен берләштерелгән проектлар җыелмасы (исемлеге);

дәүләт программасының дәүләт заказчысы-яраштыручысы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы һәм (яки) федераль башкарма хакимият органының территориаль органы, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт программасын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү барышында дәүләт заказчысы эшчәнлеген яраштыруны тәэмин итүче структур бүлекчәсе;

дәүләт программасының, ведомство максатчан программасының дәүләт заказчысы – программаны эшләү һәм тормышка ашыру өчен, шулай ук аны гамәлгә ашыруга бирелгән акчаны максатчан файдалану өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы һәм (яки) федераль башкарма хакимият органының территориаль органы;

дәүләт программасын, максатчан ведомство программасын үтәүчеләр – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы һәм (яки) федераль башкарма хакимият органының территориаль органы, дәүләт программасы, ведомство максатчан программасы яки ярдәмче программаның (ярдәмче программаларның) бер яки берничә чараларын эшләү һәм тормышка ашыру өчен җаваплы булган федераль бюджет акчасы, Татарстан Республикасы бюджет һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетлары акчасы белән бүтән баш эш итүчеләр»;

1.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт программасы ярдәмче программаларны, ведомство максатчан программаларны, чаралар планнарын, проектларны һәм аларның портфельләрен үз эченә алырга мөмкин.»;

1.6 нчы пунктның тугызынчы абзацында «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт программасы, максатчан ведомство программасы, проект һәм проектлар портфеле буенча тәкъдимнәр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яки) федераль башкарма хакимият органының территориаль органнары, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының структур бүлекчәләре (үз теләге белән, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәләре һәм карарлары нигезендә), иҗтимагый берләшмәләр, фәнни һәм башка оешмалар тарафыннан башлап бирелергә мөмкин.»;

1.7 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Элегрәк расланган дәүләт программаларына, ведомство максатчан программаларына үзгәрешләр кертү дәүләт заказчысы (дәүләт заказчысы-яраштыручысы) тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

4.2 нче пунктта:

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Файдаланыла торган күрсәткечләр (индикаторлар) дәүләт программасы, ведомство максатчан программасы һәм ярдәмче программалар максатларына, бурычларына һәм чараларына (чаралар төркемнәренә) ирешүне тасвирларга, еллар буенча планлаштырылган мәгънәләре булырга һәм үлчәнә алырга тиеш. Дәүләт программасы күрсәткечләре (индикаторлары) өч төркемгә бүленергә мөмкин:

дәүләт программасы, ведомство максатчан программасы һәм ярдәмче программалар максатларына һәм бурычларына ирешүне бәяли торган күрсәткечләр;

чаралар планын үтәүне бәяли торган күрсәткечләр;

проектлар һәм аларның портфельләрен тормышка ашыруны бәяли торган күрсәткечләр.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт программаларын формалаштырганда тиешле өлкәләрдә тормышка ашырыла торган проектлар чаралары һәм аларның портфельләре максатлары, бурычлары һәм чаралары исәпкә алына.»;

6.1.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1.2. Ведомство максатчан программаларын, проектларны һәм аларның портфельләрен, чаралар планнарын тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләме бу Тәртипнең 6.1.1 нче пункты нигезендә тиешле дәүләт программасы кысаларында карала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин